ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРЫССУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

№25 Иске Урыссу ав. 22 декабрь 2017 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советының 2017 елның 29 мартындагы “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында”гы 5 санлы карарына өстәмәләр кертү турында (2017 елның 28 июлендәге 11 санлы карар редакциясендә)

Ютазы районы прокурорының 2017елның 28 сентябрендәге 02-08-01-2017 санлы протестын карап, 2007 елның 2 мартындагы “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы 25-ФЗ санлы Федераль законга 2017 елның 26 июлендәге 192-ФЗ санлы Федераль законы нигезендә кертелгән үзгәрешләр нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советының 2017 елның 29 мартындагы 5 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (2017елның 28 июлендәге 11 санлы карар редакциясендә) түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

12 маддәнең 1 өлешендәге 10 пунктына түбәндәге сүзләр өстәргә:

"- күрсәтелгән бәяләмәгә карата Россия Федерациясенең тиешле субъектының чакырылыш комиссиясенә шикаять бирү өчен билгеләнгән срок тәмамланган көннән алып 10 ел дәвамында, әгәр күрсәтелгән бәяләмә һәм (яисә) Россия Федерациясенең тиешле субъектының чакырылыш комиссиясе карары гражданның күрсәтелгән бәяләмәгә шикаяте буенча судка шикаять ителгән булса, - күрсәтелгән Бәяләмәне һәм (яисә) Россия Федерациясе тиешле субъектының чакырылыш комиссиясе карарын гражданның күрсәтелгән бәяләмәгә шикаяте буенча чыгарганда гражданның хокуклары бозылмаган дип танылган суд карары закон көченә кергән көннән алып 10 ел дәвамында».

2. Әлеге карарны Иске Урыссу авылы, Совет урамы, 16в йортта урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Ютазы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

Урыссу авыл җирлеге башлыгы Р.С. Мөхәмәтҗанова